**Класс:** 5

**Укытучы:** Шакирова Рузилә Рәисовна

**Программа:** Вигасин А.А. Гомуми тарих. Борынгы заман тарихы. 5 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы / - Казан: Татар.кит. нәшр., 2020.

**Тема:** Афина мәктәпләрендә һәм гимнасийләрендә

**Максаты**: Укучыларны Афина мәктәпләре һәм гимнасийлары эшчәнлеге белән таныштыру; тарих фәненә, спортка кызыксыну тәрбияләү

**Планлаштырылган нәтиҗә:** яңа терминнарны үзләштерү.

**I. Лекция.**

Исәнмесез, укучылар! Бугенге дәрестә Афина мәктәпләре һәм гимнасийләре турында сөйләшербез**. (2 слайд)** Ә сез аларның аермасы нәрсәдә икәнен беләсезме? Нәрсә ул палестра? Әгәр әлеге сорауларга җавап белмәсәгез яңа теманы тыңларга киңәш итәм.

План

- педагог коллар
- мәктәптә дәресләр
- палестрага йөрү
- Афина гимнасияләрендә.

**(3 слайд)** Борынгы грек балаларының ничек үсүләре турында без бик күп мәгълүмат белмибез. Шулай да, тәрбиянең ничек булуы турында, төрле вазаларда калган рәсемнәр сөйли. **(4 слайд)** Хәлле гаиләләрдә малайлар җиде яшькәчә уен белән генә мавыкканнар. Алар кыршау яки туп атып уйнаганнар, балчыктан өйләр ясаганнар, балавыздан кеше һәм хайван сыннарын әвәләгәннәр. Җиде яшьтә аларны педагогка тапшырганнар.

**Укучылар, кем булган соң ул педагог? Әйдәгез бу сорауга җавап эзлик.**

**(5 слайд)** Педагог - грек теленнән тәрҗемә иткәндә “баланы озатып йөрүче” дигәнне анлата. Педагог малайны көн саен мәктәпкә йөрткән, аның язу әсбапларын, музыка уен коралларын күтәреп барган. Өйдә ул аны яхшы

гадәтләргә  - өстәлдән рөхсәтсез бернәрсә дә алмаска, аякны аякка куеп утырмаска, каты кычкырып көлмәскә, өлкәннәр күренсә, торып басарга өйрәткән.

Педагог итеп картайган яки гарипләнгән, башка эшкә ярамаган колларны куйганнар. Еш кына педагог хәтта грекчада сөйләшкән, сукранучан булган, бала аз гына ул дигәнчә эшләмәсә, чыбыкка ябышкан. Педагогларны алама киемле, таралган сакаллы пеләш карт итеп сурәтләгән балчык сыннар сакланган.

**(6 слайд)** Таң атканда шәһәр һәм авыл малайлары мәктәпкә ашыканнар. Шул мәктәпләрнең берсенә күз салыйк.

**(7 слайд)** Кулына үгез койрыгыннан ясалган камчы тоткан укытучы текст әйтеп яздыра: “Надан кеше – җирдәге иң кыргый зат”. Нәни укучылар бу сүзләрне балавыз сөртелгән тактачыкларга төшерәләр. **(8 слайд)** Хәрефләрне металл яисә сөяктән ясалган таякның очлы башы белән басып язалар. Ул таяк стиль дип атала. Әгәр язуда хата китсә, таякның икенче яссы башы белән сөртеп төзәтәләр. Өлкән яшьтәге укучылар, тактачык һәм стильдән кала, папирус һәм камыш каләм кулланалар.

Язу һәркемгә дә җиңел бирелмәгән. Бер бай үзенең ялкау улына исемнәре алфавиттагы хәрефләргә башланган 24 бәләкәй кол бүләк иткән дип сөйләгәннәр.

**(9 слайд)** Мәктәпләрдә укырга һәм язарга, санарга һәм рәсем ясарга өйрәткәннәр. Гомер һәм башка шагыйрьләрнең шигырьләренә мәхәббәт тәрбияләгәннәр. Афиналылар музыкага мәхәббәттән башка чын кеше булырга мөмкин түгел дип раслаганнар. Шуңа күрә балалар флейтада һәм башка коралларда уйнарга, хорда җырлау сәнгатенә өйрәнгәннәр. Мәктәптә балалар 7 яшьтән 12 яшькә кадәр укыганнар.

**(10 слайд)** Малайлар, яз көне була торган каникуллардан тыш, Марафон һәм Саламин сугышында җиңү көннәрендә мәктәпкә бармаганнар. Грек аллалары хөрмәтенә үткәрелә торган хисапсыз бәйрәм көннәрендә дә укымаганнар. Уку түләүле булган.

**(11 слайд)** Кызлар өчен мәктәпләр булмаган. Ана кеше үзендә булган белемне кызларына да өйрәткән. Кызларны укырга, язарга, җырларга, биергә, иң мөһиме йорт эшләренә өйрәткәннәр.

**(12 слайд)** Малайлар, унике яшьләре тулгач, тагын бер мәктәпкә йөри башлаганнар, биредә алар гимнастика – көрәш, йөгерү, сикерү, сөңге һәм тәлинкә ыргыту белән шөгыльләнгәннәр. Мондый мәктәпне палестра дип атап йөрткәннәр. Дәресләр дүртпочмаклык рәвешендәге ишегалдында ачык һавада, явымлы көннәрдә түбә астында, ишегалдын әйләндереп алган портикларда үткәрелгән.

**(13 слайд)** Палестрадагы гимнастика дәресен дә колонналар белән уратып алынган ишегалдында малайлар көрәшергә өйрәнә. Бәйгедә җитез һәм көчле, төрле алымнарны яхшы белгән малай гына җиңеп чыга ала. Аларның берсе көтмәгәндә ярышташын тез аркылы ыргыта, әгәр дә тегесенең гәүдәсе өч тапкыр җиргә тисә, ул җиңгән булып санала. Таләпчән укытучы ярыш тәртипләрен бозган һәр укучыга кулындагы таягы белән сугарга әзер тора. Икенче пар көрәшергә үз чиратын көтә. Алар учларына күп итеп май салалар һәм шуның белән тәннәрен ялтыратып уалар. Барысы да ялангач килеш көрәшә. Дәрестән соң, гөр килеп, тәннәрендәге майны һәм тирне юарга йөгерәләр. Һәр палестра каршында кое, фонтан, кайчакта хәтта мунча да була.

**(14 слайд)** Палестрада атлетларның бөек грек осталары ясаган сыннары торган. Тәлинкә ыргытучы атлет сыны бөтен дөньяда мәгълүм. Аны ясаган кеше – Мирон – бу сында хәрәкәтне күрсәтеп бирә алган. Атлет менә-менә тураеп баса да, гаять зур көч белән этеп җибәргән тәлинкәсе еракка очып китәр кебек. Поликлет ясаган сөңге ыргытучының бронза сыны да яхшы билгеле. Бу сында һәр егетнең физик яктан көчле, матур, үз полисы өчен батырлыклар эшләргә әзер торган граждан булырга тиешлеген күрсәтелгән.

**(15 слайд) Укучылар, сез ничек уйлыйсыз, гимнасийләрдә кемнәр белем алган икән?** Гимнасийләрдә өлкән яшьтәге афиналылар белем алганнар.

Алар гимнастика белән шөгыльләнүләрен дәвам иттерергә теләсәләр, Афинадагы өч гимнасийның берсенә йөргәннәр.

Гимнасийләр шәһәр читендә, яшел агачлар һәм болыннар арасында урнашкан. Аларда атлетлар шөгыльләнер өчен мәйданчыклар, бассейннар, чишенү бүлмәләре һәм ял итү, дусларча сөйләшеп утыру урыннары булган.

**(16 слайд)** Гимнасийләрдә күпсанлы тыңлаучылар алдында танылган галимнәр чыгыш ясаган. Алар Галәм төзелеше турында үз карашларын аңлатканнар, югары белемле кешеләр, галимнәр идарә итәргә тиешле үрнәк дәүләт төзү планнарын тәгъдим иткәннәр.

Гимнасийләрдә матур сөйләргә - халык җыелышларында һәм судларда чыгыш ясарга да өйрәткәннәр.

**(17 слайд)** Димәк, укучылар Грециядә тәрбия һәм белемне балалар өйдә, мәктәптә, палестрада, гимнасийларда алганнарын белдек.

**II Практик эш**

**Беренче бирем**

Таблицадагы буш урыннарны тутырыгыз

| **Аңлатма** | **Термин** |
|---|---|
| Педагог | |
| Стиль | |
| Палестра | |

**Җаваплар:**

Таблицадагы буш урыннарны тутырыгыз

| **Аңлатма** | **Термин** |
|---|---|
| Педагог | баланы озатып йөрүче |
| Стиль | Сөяктән яки металлдан ясалган язу таякчыгы |
| Палестра | Афинада гимнастика мәктәбе |

**Икенче бирем**

**Тексттагы хаталарны табыгыз һәм языгыз.**

Афинада мәктәпкә малайлар сигез яшьтән барганнар. Уку бушлай булган. Дәресләрне педагоглар укытканнар. Мәктәптә уку, музыка һәм архитектура фәннәре кергән. Палестрада малайлар гимнастика һәм йорт эшләре алып барырга өйрәнгәннәр. Гимнасийяләрдә төрле галимнәрнең чыгышларын тыңлаганнар.

**Җаваплар**

**Тексттагы хаталарны табыгыз һәм язгыз.**

Афинада мәктәпкә малайлар (~~**сигез**~~) **җиде** яшьтән барганнар. Уку (~~**бушлай**~~) түләүле булган. Дәресләрне (~~**педагоглар**~~) **укытучылар** укытканнар. Мәктәптә уку, музыка һәм (~~**архитектура**~~) фәннәре кергән. Палестрада малайлар гимнастика һәм (~~**йорт эшләре**~~) алып барырга өйрәнгәннәр. Гимнасийяләрдә төрле галимнәрнең чыгышларын тыңлаганнар.

**Өченче бирем.**

| **Мәктәпнең тибы** | **Укучының яше** | **Нәрсәгә өйрәнгәннәр** |
|---|---|---|
| **Мәктәп** | | |
| **Палестра** | | |
| **Гимнасия** | | |

**Җаваплар:**

| **Мәктәпнең тибы** | **Укучының яше** | **Нәрсәгә өйрәнгәннәр** |
|---|---|---|
| **Мәктәп** | 7-12 яшькә | Укырга, язарга, санарга, рәсем ясарга. |
| **Палестра** | 13-16 яшькә | Гимнастика, көрәш, сикерү, сөңге һәм тәлинкә ыргыту. |
| **Гимнасия** | 16-18 яшькә | Матур сөйләргә, җыелышларда чыгыш ясарга, фәнни |

| | | |
|---|---|---|
| | | белемнәргә өйрәнгәннәр |

**Дүртенче бирем**

**Өлешләрдән акыл иясе Аристотельның фикерләрен җыегыз.**

| | |
|---|---|
| Колларның бер ишләре җанлы | җанлы һәм барлык кораллар арасында да иң камиле |
| Дус – ул бер җан | икенчеләре җансыз |
| Кол - | ике тәндә яши торган |

**Җавап:**

| | | |
|---|---|---|
| Колларның бер ишләре җанлы | икенчеләре җансыз | |
| Дус – ул бер җан | ике тәндә яши торган | |
| Кол - | җанлы һәм барлык кораллар арасында да иң камиле | |